Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советы карары

16.09.2016ел. № 33/1

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Ял итү, халык күп җыела торган урыннарда, су объектларының су саклау зонасын кулланганда хокук бозуларны кисәтү максатыннан Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә (алга таба-кагыйдәләр) Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Советының 06.09.2011 ел, № 24 карары белән расланган түбәндәге үзгәрешне кертергә::
1.1. Кагыйдәләрнең 7.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7.9. Автотранспорт чараларын ял итү урыннарында, кешеләр күпләп яши торган урыннарда, пляжларда, скверларда бу максатлар өчен бүлеп бирелгән урыннарда, шулай ук тротуарларда, газоннарда һәм урамнарда туктау тыела.»

2. Бу карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерү:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;
- ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;
-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16 йорт; шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Олы Кариле авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Кариле авыл җирлеге Советы Рәисе Ф.Г Гарифуллин